| | |
|---|---|
| СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>БУРНАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 17.10.2022 | с. Татарское Бурнашево | 23-126 |

Торак пункт территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен Борнаш авыл җирлеге составына керүче Татар Борнашы авылы торак пунктының территориясе чикләрен билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Торак пункт территориясенең бу өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

   Татар Борнашы авылы:
   Яңа, Яшьләр, Луговая, Садовая, Дубравная, Зеленая урамнарында.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Борнаш авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин